**ГЛАВА ТАТАРСКО-ЯНТЫКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422634 с. Татарский Янтык,
ул.Магазинная, д 31 а.
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАТАР ЯНТЫГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422634 Татар Янтыгы авылы,
Кибет урамы, 31 а нчы йорт
Тел/факс 8-(378) -3-26-21

2023 елның 27 октябре 2 номер

# КАРАР

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегенең Татар Янтыгы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Татар Янтыгы авыл җирлеге, Татар Янтыгы авылы, Кибет урамы, 31а йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йортында Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең Татар Янтыгы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2023 елның 24 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Муниципаль район Татар Янтыгы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 2024 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юллауга сез ризамы?

- Татар Янтыгы торак пунктында Мәктәп, Казан урамнары буенча су белән тәэмин итү системасын төзү, ремонтлау, реконструкцияләү (материал алу, йөк ташу, торбалар салу, килешү буенча эш өчен түләү, ПСД һәм технадзор).

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-

http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы**
**авыл җирлеге Советы рәисе : Н.Ш. Мифтахов**